ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июль, 2026 ел № 8/7

Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 21 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә (Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/12, 2018 елның 27 апрелендәге 24/9, 2022 елның 23 июнендәге 15/11, 2024 елның 7 августындагы 35/15, 2026 елның 8 маендагы 7/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктта:

а) 4 пунктчада «даими йөртү муниципаль маршруты буенча даими йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими йөртү маршрут карталарын бирә» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукын бирә;» сүзләренә алыштырырга;

б) 4.1 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

2) 10.1 пунктта «даими йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирелгән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы бирелгән» сүзләренә, «мондый таныклыкларның һәм карталарның» сүзләрен «мондый хокукның» сүзләренә алыштырырга;

3) 13 пунктта түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Даими йөртү муниципаль маршруты буенча даими йөртүне гамәлгә ашыру хокукы даими йөртү муниципаль маршрутлары реестрындагы язма белән раслана.»;

4) 16 пунктта түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Даими йөртү муниципаль маршрутлары реестры электрон чыганакларда алып барыла.»;

5) 18 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«18. Даими йөртү маршрутлары реестрына Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешендә каралган мәгълүматлар кертелергә тиеш. Даими йөртү муниципаль маршрутлары реестрына кертелгән мәгълүматлар (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны турындагы мәгълүматтан тыш) вакәләтләренә әлеге реестрларны транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән форма буенча алып бару керә торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органының рәсми сайтында яисә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.»;

6) 8 бүлек исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«8 бүлек. Даими йөртүнең муниципаль маршрутында йөртү хокукын һәм тиешле маршрут карталарын бирү, бирелгән хокукның гамәлдә булуын туктату»;

7) 31 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә, «һәм тиешле маршрут карталары бирелә» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алыштырырга;

8) 32 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә, «һәм тиешле маршрут карталары бирелә» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алыштырырга;

9) 33 пунктта:

а) беренче абзацта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә, «һәм тиешле маршрут карталары бирелә» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алыштырырга;

б) 1 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Федераль законның 29 статьясы 1 өлешендәге 1, 2, 7, 9 һәм 11 пунктларында каралган хәлләр килеп чыкканнан соң һәм даими йөртүне гамәлгә ашыруның ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән яңа хокукы нигезендә даими йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганга кадәр. Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә каралган шартлар буенча, узмаган дип танылган ачык конкурста җиңүчегә даими йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртү хокукы бирү рөхсәт ителми.»;

в) 3 пунктчада «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә, «бирелгән» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алыштырырга;

10) 33.1 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә, «һәм тиешле маршрут карталары бирелә» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алыштырырга;

11) 34 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«34. Ачык конкурс уздырмыйча йөртү маршруты буенча йөртү гамәлгә ашыру хокукы аны бирү өчен нигез булган хәлләр килеп чыккан көннән алып өч көн эчендә бер тапкыр 180 көннән артмаган вакытка, ә шундый хәл әлеге маршрутта йөртүне гамәлгә ашыруның элек бирелгән хокукының гамәлдә булуын туктатылып торган очракта, күрсәтелгән хокукның гамәлдә булуын туктатып тору вакытына бирелә.»;

12) түбәндәге эчтәлектәге 34.1. пункт өстәргә:

«34.1. Даими йөртүнең муниципаль маршрутында даими йөртү карталары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әлеге маршрутны билгеләгән вәкаләтле органы яисә Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль маршрутта йөртү хокукы бирелгән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга бирелә. Даими йөртүнең күрсәтелгән маршрут карталары юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыга даими йөртүнең тиешле маршрутында йөртү хокукы бирелгән вакытка бирелә.»;

13) 10 бүлек исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«10 бүлек. Даими йөртү маршрутында йөртү хокукының гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору»;

14) 42 пунктта:

а) беренче абзацта «гамәлгә ашыру турында таныклык биргән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы тапшырылган» сүзләренә, «әлеге таныклыкны» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы тапшырылган» сүзләренә алыштырырга;

б) 2 пунктчада «әлеге таныклыкны» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы тапшырылган» сүзләренә алыштырырга;

в) 7 пунктчада «гамәлгә ашыру турында таныклык биргән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы тапшырылган» сүзләренә алыштырырга;

15) 43 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алыштырырга;

16) 44 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«44. Әлеге Тәртипнең 42 пункты 3 пунктчасында каралган хәлләр буенча даими йөртү муниципаль маршруты буенча йөртүне гамәлгә ашыру хокукының гамәлдә булуы 90 көн узгач туктатыла, ә мондый хокук вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән очракта - әлеге хокукның гамәлдә булмавы турында вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына, вәкаләтле органга гариза кергән көннән соң 10 көн узгач туктатыла.Татарстан Республикасы башкарма хакимияте яисә башкарма комитет. Күрсәтелгән срок тәмамланганчы мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы даими йөртү муниципаль маршрутында йөртүне хокукында каралган даими йөртүне гамәлгә ашырырга тиеш.»;

17) 45 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы тапшырылган» сүзләренә алыштырырга;

18) 46 пунктта:

а) беренче абзацта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алыштырырга;

б) 2 пунктчада «әлеге таныклык бирелгән» сүзләрен «хокук тапшырылган» сүзләренә, «таныклык» сүзен «хокук» сүзенә алыштырырга;

в) 5 пунктчада «әлеге таныклык бирелгән» сүзләрен « әлеге хокук тапшырылган» сүзләренә алыштырырга;

19) 47 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алыштырырга;

20) 48 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алыштырырга;

21) 49 пунктта «гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы тапшырылган» сүзләренә, «әлеге таныклыкны биргән» сүзләрен «әлеге хокукны тапшырган» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев